**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы карары**

Уразай авылы №172-27 «24» апрель 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 нче февраленнэн 167-24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карра итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2020 елның 27нче февраленнэн 167-24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәләр кертергә:

1.1. 52 статьяның икенче абзацында "Федераль казначылык органнары счетларыннан" сүзләрен "керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларыннан" сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 53 статьяда:

а) 3 пунктта «түләүләр һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр» сүзләренә алмаштырырга (алга таба - күрсәтмә) һәм;

б) 5 пунктта «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ruhttp://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Уразай авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шэрифуллина